УДК 929

# Ш. Мәрҗани чорында Юнысов мәхәлләсе (метрика язмалары нигезендә)

*Э. К. Сәлахова,*

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты,*
*Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# Yunusov's Mahalla of Kazan during Sh. Mardzhani's era (based on the materials of registries)

*E. K. Salakhova,*

*Sh. Mardzhani Institute of History, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan,*
*Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**
Первая соборная мечеть, ныне носящая имя выдающегося религиозного деятеля Шигабуддина Марджани, является одной из самых древних и первых в г. Казани каменных мечетей, построенных после покорения Казанского ханства. В XIX в. в народе приход этой мечети стал называться Юнусовской махаллей, по фамилии И. Юнусова, который стал неформальным главой первой казанской общины. Ш. Марджани, выпускник знаменитых медресе в Бухаре и Самарканде, по приглашению И. Юнусова поступает на престижную должность имам-хатыба и мударриса Первой соборной мечети. Целью данного исследования является изучение Юнусовской махалли и малоизвестных фактов из жизни ученого в период его проживания и службы в Старотатарской слободе на материалах метрических книг. Впервые в подобных исследованиях метрические книги привлекаются как исторические источники. В статье рассматривается состояние и жизнь прихода в годы службы Ш. Марджани имамом Юнусовской мечети. Автор дает информацию об истории и развитии Юнусовского прихода, показывает социальный статус жителей, выделяет имена знатных родов. На материалах метрических книг приводится статистический материал о родившихся и умерших данного прихода с 1863 по 1889 г. Материалы метрических книг позволили выявить неизвестные факты жизни Ш. Марджани и его близких, которые впервые представлены в данной публикации.

**Abstract**
The first cathedral mosque, currently named after the outstanding religious leader Shigabutdin Mardzhani, is one of the first and oldest stone mosques in Kazan built after the conquest of the Kazan Khanate. In the 19th century, the parish of this mosque was called Yunusov's Mahalla derived from the name of I. Yunusov who became the informal leader of the first Kazan community. Sh. Mardzhani, being a graduate of the famous madrasahs in Bukhara and Samarkand, was invited by I. Yunusov to get appointed to the prestigious position of Imam khatib and mudarris

of the First Cathedral Mosque. The purpose of this work is to study Yunusov's Mahalla and little-known facts from the life of the scholar during his residence and work in the Starotatarskaya settlement based on the materials of registries. For the first time registries are represented as historical sources. The article considers the state and life of the parish during Sh. Mardzhani's serving as Imam at the Yunusov Mosque. The author provides information on the history and development of the Yunusov's parish, shows the social status of the inhabitants, and identifies the names of noble dynasties. Based on the materials of registries, the statistics of births and deaths in the parish from 1863 to 1889 is represented. Materials of registries allowed us to provide insight into the unknown facts of the biographies of Sh. Mardzhani and his relatives which are presented in the publication for the first time.

**Ключевые слова**
Ш. Марджани, история татарского народа, мусульманский приход, мечеть, метрические книги, религиозные деятели татарского народа, Первая соборная мечеть.

**Keywords**
Sh. Mardzhani, history of Tatars, Muslim parish, mosque, registries, Tatar religious figures, First Cathedral Mosque.

Казан ханлыгы үз мөстәкыйльлеген югалтканнан соң, халыкның рухи тормышы белән бәйле булган оешмалары, мәчет, мәктәпләре дә юкка чыга. Хәзерге вакытта Шиһабетдин Мәрҗани исемен йөрткән мәчет татар халкы дәүләтчелеген югалтканнан соң Казан шәһәрендә төзелгән иң борынгы мәчетләренең берсе. Ул үзенең тарихын 1767 елдан башлый, императрица Екатерина II рөхсәте белән төзелгән бу мәчет Казан татар җәмгыятенең үзәгенә әверелә.

XIX йөздә халык телендә Юнысовлар мәхәлләсе буларак билгеле булган мәхәлләнең тарихы гаять кызыклы һәм шул чор Казан татар җәмгыятенең яшәү халәтен ачыкларга мөмкинлек бирә. Бу мәхәлләдә билгеле кешеләр, нигездә, бай катлам вәкилләре яшәгән. Ш. Мәрҗани анда имам итеп билгеләнгәч, Юнысовлар мәхәлләсе татар җәмгыятенең рухи, гыйлемлелек үзәгенә әйләнә. Мәкаләнең максаты – Ш. Мәрҗани имамлык иткәндә Юнысов мәхәлләсенең халәте, халкының яшәешен күрсәтү, социаль катламын өйрәнү һәм Шиһабетдин Мәрҗани тормышындагы яңа билгеле булмаган фактларны ачыклау. Бу хезмәтнең үзенчәлеге – әлегә кадәр фәнни әйләнештә актив кулланылмаган чыганаклар – Беренче җәмигъ мәчете метрика кенәгәләре нигезендә эшләнә һәм шул материалларга таянып ясалган нәтиҗәләрне чагылдыра. Ш. Мәрҗани тормышы, аның эшчәнлеге белән бәйле яңадан-яңа фактлар ачыклану – Мәрҗани иҗатын өйрәнү, аның белән бергә татар җәмгыяте тарихын өйрәнү өчен кыйммәтле материаллар булып тора. Аның актуальлеге дә шуның белән билгеләнә.

Метрика кенәгәләре – һәр мәхәллә каршында алып барылган теркәү кенәгәләре. Бу кенәгәләргә мәхәлләдә туган һәм үлгән барлык кешеләр дә язылып барган, укылган никахлар, кылынган талаклар да шул кенәгәнең бер сәхифәсе итеп теркәлеп барган[1]. Бер яктан бары тик фактларны гына туплаган бу кенәгәләр мәгълүмат ягыннан шактый коры кебек тоелсалар да, комплекслы тикшергән вакытта, чагыштырма метод алымнарын кулланып эш иткәндә шул чорның тулы картинасын ача.

Ш. Мәрҗанинең Казанда имамлык итү чорын, аның аралашу даирәсен чагылдыра торган уникаль беренчел чыганаклар булып Казанның Беренче җәмигъ мәчете документлары тора. Иске таш мәчет Казанның яше ягыннан иң олы һәм дә иң абруйлы мәчетләренең берсе була. Бу мәчеттә заманының абруйлы руханилары имамлык икән. Беренче имамнарыннан (1762 елда билгеләнә) чыгышы белән Иске Татар

бистәсеннән булган Әбүбәкер Ибраһимов (Әбүбәкер бине Ибраһим бине Йосыф бине Ишбулат бине Ишморат), аның вафатыннан соң вакытлыча имамлык вазифасын үтәгән тумышы белән Тәтеш өязе Ташкичү авылыннан булган Солтангали Акаев билгеле. 1794 елдан башлап төпле дини белем иясе, мәчет каршында зур мәдрәсә булдырган Ибраһим Хузяш, аның вафатыннан соң әлеге мәчет имамы булып Мостафа Мусин (Мостафа бине Муса бине Иманкол бине Иманай бине Котлыгъ бине Үзбәк бине Илкәй әл-Казани) шәһәрнең өченче мәхәлләсеннән күчеп килә. Ислам дөньясының үзәкләре Бохарада, Кабулда белем өстәгән, халык арасында Коръән хафиз буларак танылган бу хәзрәт вафатыннан соң, имамлыкка чыгышы белән Казан арты Бәрәскә авылыннан булган Сәгыйдь бине Хәмид бине Солтан сайлана.


XIX гасыр башында шактый баеп киткән сәүдәгәр Юнысовлар нәселе мәхәлләне үз кулына ала. Алар мәчетне төзәтү, бинаны яңарту, мәдрәсә чыгымнары өчен дә, имам, мөәззиннәр, мөгаллимнәргә дә акча бирәләр, расходларны күтәрәләр[2]. Әлбәттә инде, акча биргәч, аларның халык арасында авторитетлары да күтәрелә. Бу гамәлләре нигезендә мәхәллә эшләрен көйләү, аның белән идарә итүдә дә аларның тәэсире имамныкына караганда да зуррак була.

Шуңа бу чордан башлап халык арасында мәхәллә – Юнысовлар мәхәлләсе буларак танылa. Мәчет, имамлык, мәдрәсә эшләренә дә тыкшыну башлана. Шул хәлне кабул итә алмыйча, мулла Сәгыйдь бине Хәмит имамлыктан ваз кичеп, 1848 елда хаж сәфәренә чыгып китә. Имамсыз калган мәчеткә имам сайлау, аны табуны



*Мәрҗани мәчете. Рәссам И. Айдаров.*

*The Mardzhani Mosque. Painter I. Aydarov.*



*Ш. Мәрҗани кулы белән тутырылган метрика кенәгәсе. 1881 ел. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф. 180 тасв., 2 эш, 428 кгз.*

*The metric filled in by Sh. Mardzhani. 1881. The State Archive of the Republic of Tatarstan, fond 204, series 180, file 2, p. 428.*

Ибраһим бине Гобәйдулла Юнысов (халык арасындагы исеме – Озын Ибрай) үз кулына ала. Аның фикере буенча, мәхәлләгә иң белемле галим, мөдәррис булырлык кеше куелырга тиеш була. Таныш байлар аша Бохарадан әле генә белем алып кайткан егет турында ишетеп, Ибраһим Юнысов аны – Шиһабетдин Мәрҗанине голямалар мәҗлесенә чакыра. Бу мәҗлестә үзен галим итеп күрсәтә алган Шиһабетдин хәзрәт Ибраһим Юнысов мәхәлләсендә 1849 елның 28 ноябрендә беренче җомга намазын укыта[3]. Ул 1850 елның 19 февралендә Диния нәзарәтеннән имамлык шәһадәтнамәсе ала. Ш. Мәрҗани имамлык иткән мәхәллә Казанның үзәгендә урнашу белән генә түгел, ә иң абруйлы мәхәллә булу белән дә шул чорның бай, абруйлы катламын үз эченә алган. Мәхәлләнең метрика китапларыннан билгеле булганча, биредә теркәлгәннәрнең зур күпчелеген мещан, сәүдәгәр катламыннан булган кешеләр тәшкил иткән. Бу мәхәллә метрикасы битләрендә атаклы нәселләрдән Әҗемев, Апанаев, Аппаков, Галиев, Аитов, Айтуганов, Ишиев, Ямашев, Бакиров, Рәфиков, Залушев, Кашаев, Бикшиев, Балаков, Аблаев, Рахманколов, Ямашев һәм башка фамилияләр бар.

Казанның сәүдәгәр һәм мещан катламыннан кала бу мәхәлләдә Казан губернасының төрле өязләреннән килгән кешеләр дә гомер иткән. Шул чор Казан шәһәренең татар җәмгыятенең үзәге булган – Иске Татар бистәсенә бай, мөлкәтле авыл кешеләре күченеп килгәннәр. Күпчелекне, әлбәттә, Казан шәһәренә якын урнашкан, Казан өязе авылларыннан чыгучылар тәшкил итә, болардан кала чыгышлары белән Тәтеш, Мамадыш, Лаеш өязләреннән булган кешеләр дә сан ягыннан шактый. Чистай, Царевококшайск өязе авылларыннан да берничә кешенең бу мәхәлләгә каравы метрика язмаларында чагыла. Шулай ук Буа сәүдәгәре Гайнулла бине Вәлиулла, Малмыж сәүдәгәре Гали бине Шакир үз балаларының тууларын бу мәхәлләдә теркәткән[4].

**Юнысовлар мәхәлләсендә туу, никах,
талак һәм вафат булучылар хакында мәгълүмат***

| Дата (ел) | Туган балалар | | Никах | Талак | Вафат булучылар | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Ир балалар | Кыз балалар | | | Ир-атлар | Хатын-кызлар |
| 1863 | 20 | 27 | 14 | 2 | 16 | 16 |
| 1864 | 16 | 15 | 17 | 1 | 20 | 22 |
| 1865 | 16 | 19 | 13 | 3 | 16 | 30 |
| 1866 | 15 | 13 | 12 | 2 | 32 | 42 |
| 1867 | 15 | 21 | 11 | 5 | 12 | 17 |
| 1868 | 27 | 17 | 15 | 0 | 23 | 22 |
| 1869 | 21 | 15 | 18 | 3 | 39 | 15 |
| 1870 | 20 | 16 | 22 | 4 | 25 | 17 |
| 1871 | 19 | 18 | 16 | 5 | 12 | 17 |
| 1872 | 14 | 14 | 17 | 2 | 22 | 19 |
| 1873 | 21 | 16 | 21 | 3 | 16 | 14 |
| 1874 | 22 | 15 | 18 | 4 | 13 | 19 |
| 1875 | 24 | 26 | 12 | 2 | 27 | 23 |
| 1876 | 20 | 16 | 14 | 4 | 19 | 11 |
| 1877 | 22 | 26 | 9 | 4 | 21 | 18 |
| 1878 | 10 | 16 | 20 | 3 | 32 | 34 |
| 1879 | 26 | 22 | 17 | 0 | 11 | 21 |
| 1880 | 26 | 20 | 16 | 1 | 19 | 14 |
| 1881 | 20 | 11 | 11 | 0 | 25 | 27 |
| 1882 | 22 | 14 | 9 | 1 | 19 | 25 |
| 1883 | 16 | 22 | 18 | 2 | 16 | 13 |
| 1884 | 21 | 20 | 25 | 7 | 20 | 21 |
| 1885 | 21 | 27 | 24 | 4 | 22 | 25 |
| 1886 | 15 | 17 | 16 | 4 | 15 | 29 |
| 1887 | 20 | 22 | 20 | 1 | 21 | 16 |
| 1888 | 29 | 26 | 15 | 2 | 19 | 22 |
| 1889 | 23 | 16 | 20 | 6 | 23 | 21 |

Беренче җәмигъ мәчете мәхәллә халкының саны, анда барган демографик халәт таблицада ачык чагыла. Саннардан күренгәнчә, XIX йөзнең икенче яртысында, Ш. Мәрҗани имамлык иткән елларда, мәхәллә зур булган. Мәхәлләнең зурлыгын бу мәчет метрика саннарында теркәлгән никахлар саны белән билгеләп була. Никах саны күп булу – мәхәлләнең җанлылыгын, зурлыгын күрсәтә торган фактор. Шулай ук никах белән талак саннарының чагыштырмасы да никах файдасына шактый зур булуы – мәхәллә халәтенең тотрыклык күрсәткече. Монда мәхәлләнең рухи тормышы, аның рухи тормышында имамының роле барлыгын танырга кирәк.


Ш. Мәрҗани бу мәхәлләдә 1850 елдан башлап, вафатына чаклы, 1889 ел башына кадәр имамлык итә. Шушы еллар аралыгында 1854 елның 21 августыннан яше тулмаган кызга никах укыган дигән шикаять нигезендә аның Указы алына, имамлыктан һәм мәдрәсәдә дәрес бирүдән читләштерелә. Замандашлары сүзләре буенча, бу эштә

* Беренче Таш мәчет метрика кенәгәләре нигезендә эшләнде (кара: Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф., 180 тасв., 2 эш).

мәхәлләнең элекке имамы хаҗ сәфәреннән кайткан Сәгыйдь хәзрәт катнашы булган булырга тиеш, шулай ук Казан шәһәренең башка имамнарының да гыйлемле хәзрәткә көнчелеге зур була. Бу чор – мәхәлләнең, бигрәк тә Ш. Мәрҗани мәдрәсәсенең хәлен авырлаштыра, шәкертләр укуларын ташлый башлыйлар. Шул заманда полицмейстр вазыйфасында булган Шаһиәхмәд Алкинның зур ярдәме белән яңадан тикшерү нәтиҗәсендә, ягылган яга кире кагылып, 1855 елның 17 июлендә Ш. Мәрҗанигә Указы кайтарыла[5]. Әмма метрика язмаларын алып бару турындагы Синод указыннан соң тутырылган бу мәхәллә метрика язмалары безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Бу мәхәлләнең сакланган метрика язмалары бары тик 1863 елдан гына башлана. Ш. Мәрҗани эшчәнлеге белән бәйле булган чыганаклар – метрика язмаларын 1863-1889 еллар аралыгында карый алабыз. Ләкин Шиһабетдин хәзрәт бары тик 1876, 1881, 1882 елларда гына мәхәлләнең метрика язмаларын үз кулы белән тутыра. Ш. Мәрҗани гади имам түгел, ә мәдрәсә җитәкчесе, мөгаллиме, галим, җәмәгать эшлеклесе, һәм башка бик күп кенә вазифаларны башкаручы, шуңа аның мәхәлләдәге көндәлек һәр вакыйгадан хәбәрдар булып тору мөмкинлеге булмый. Гадәттә, метрика язмаларын икенче имам, яисә мөәззиннәр тутыра торган була, бары тик, авылларда метрика язмаларын беренче, яисә мәхәлләнең бердән-бер имамы тутырган.

Әлеге мәчет метрика язмалары Ш. Мәрҗанинең һәм аның гаиләсенең шушы чордагы тормышының кайбер моментларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Мәхәлләнең метрика кенәгәләре нигезендә Ш. Мәрҗани тормышына караган фактларны ачыклау бу көнгә кадәр эшләнмәгән иде, әлеге эш бу мәкалә кысаларында беренче тапкыр башкарыла. Беренчел документлар нигезендә Ш. Мәрҗани тәрҗемәи хәленең кайбер билгеле булмаган яклары ачыклана, кайбер фактларга төгәллек кертү мөмкинлеге барлыкка килә. Беренчедән, аның туу һәм вафат булу вакыты турында аерым бер сүз алып бару кирәк. Билгеле булганча, Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле турында иң тәфсилле мәгълүмат аның туууына 100 ел мөнәсәбәтле чыгарылган Шәһәр Шәрәф мәкаләсендә бирелә[6]. Ш. Мәрҗани тормыш юлының күп нечкәлекләрен үз эченә алып язылган бу мәкаләдә туу вакыты һиҗри белән 1233 елның рабигыль әүвәл аеның 7нче числосында, милади белән 1818 елның 3 гыйнварында дип күрсәтелә. Шунда ук аның 74 яшендә вафат булуы хакында да әйтелә. Димәк, 1818 елда туган 74 яшьлек Шиһаб хәзрәт арифметик санау буенча 1892 елда вафат булырга тиеш. Беренче җәмигъ мәчетнең 1889 елның метрика язмасында Шиһабетдин хәзрәтнең вафаты теркәлгән[7], анда аның 1889 елның 15 апрелендә 74 яшендә вафат булуы языла. Вафат булу фактыннан санаганда туган елы 1815 ел булып чыга. Шиһабетдин Мәрҗанинең 100 еллык юбилее да 1915 елны үткәрелә. Кайбер хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, бу һиҗри ел исәбе белән бәйле булуы ихтималы белән аңлатыла. Әгәр шулай санаганда, һиҗри белән милади ел исәбенә күчергәндә бу өч еллык аерма бәлки үзен аклыйдыр да, ә хәзер тагын 100 елдан соң бу ничек була? Гомумән, монда уйланырлык нәрсәләр бар. Метрика кенәгәсендә Шиһабетдин Мәрҗанинең вафат сәбәбе итеп, авыру исеме – шәрәтан дип языла[8]. Бу гарәп сүзе су төбендә яшәүче кысла дигән җан иясен, яисә календарьдагы дүртенче айны – зодиакаль календарь буенча кысла йолдызлыгын белдерә. Замандашлары хәтирәсе буенча, Ш. Мәрҗани ашказаны яман чире, урысча әйткәндә, рактан вафат булган. Аның вафатына сәбәп булган диагнозы шул заман врачлары тарафыннан рак дип куелып, мәхәллә имамы рак сүзен гарәпчә яза һәм шулай итеп эчтәлек үзгәрә. Монда инде Ш. Мәрҗани булганга күрә гарәпчә язу абруйлырак була дип уйлагандыр. Гәрчә башка кешеләрнең үлем сәбәбендә бары тик гади итеп шеш, яисә шеш зәхмәте дип күрсәтә.

Шул ук метрика язмалары буенча Шиһабетдин хәзрәтнең хәләлләре һәм балалары хакында да кайбер мәгълүматлар алырга мөмкин. Ш. Мәрҗани вафат булганда



*Ш. Мәрҗанинең вафаты теркәлгән метрика язмасы. 1889 ел. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф., 180 тасв., 2 эш, 340 кгз.*

*The death certificate of Sh. Mardzhani. 1889. The State Archive of the Republic of Tatarstan, fond 204, series 180, file 2, p. 340.*


аның варислары булып бер улы, ике кызы, ике хатыны кала. Улы Борһанетдин 1872 елдан указлы имам булып әтисенең эшен дәвам итә. Беренче җамигъ мәчетендә имам-хатыйб, «Мәрҗани» мәчетендә мөдәррис булып тора. Белем алуын әтисендә башлаган Борһанетдин, алты ел Истанбулда белем өстәп кайта. Атасы кебек үк туры сүзле, кызыксынучан, гыйлемле бер имам була.

Кызларының олысы Галия шул заманның атаклы шәхесе буларак танылган ханым, ул Мәрҗанинең мәшһүр шәкертләре рәтендә торган билгеле зат. Галия әтисенең якын киңәшчесе, «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлаган иң гыйлемле шәкерләренең берсе Коръәнне күңелдән белүче Коръән хафиз Галия Ш. Мәрҗанигә Коръән бастыру эшенә дә ярдәм күрсәтә. Ул Борһанетдин бине Мөхәммәд белән, соңрак имам-хатыйб, «Мәрҗани» мәдрәсәсе мөдәррисе, чыгышы белән Сембер губернасы Кече Чынлы авылыннан булган, Әбү Нәгыйм Сафиулла бине Габдулла әс-Сембери әл-Җәбәлинең никахында була (никах 1884 елда укылган). Аларның никахы шул мәхәллә метрикасында теркәлгән[9].

Кече кызы Бибихава 17 яшендә 1889 елны, Шиһабетдин хәзрәт вафатына кадәр, гыйнвар аенда 25 яшьлек Казанның Печән базары мәчетенең беренче имамы Әбү Яхъя Габдулла бине Габделкәрим бине Исхак бине Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай белән никахлашкан. Бибихава мәгърифәтле хатын булган.

Ш. Мәрҗанинең югарыда аталган балалары турында беркадәр мәгълүмат булса да, аның башка газизләре, гомерләре озын булмаган балалары хакында әдәбиятта хәбәрләр юк. Метрика язмаларындагы фактлар бу бушлыкны тутырырга, аның тормышында әлегә кадәр билгеле булмаган мәгълүматларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Ш. Мәрҗанинең Казанда имамлыгының бер елыннан соң беренче хатыны вафат була. Бибинәгыймә бинте Хөсәен бине Йосыф Апанай кызлары Бибихаваны дөньяга китереп бакыйлыкка күчә. Ш. Мәрҗани бары өч елдан соң кабат өйләнә, алга таба гомер юлдашлары – Бибифатыйма бинте Хөсәен бине Муса һәм гомеренең ахырында өйләнгән Бибизөһрә – мәшһүр Габденнасыйр әл-Буави кызы. Ш. Мәрҗанинең тормышындагы әлеге вакыйгаларны метрика кенәгәләреннән күзәтү мөмкин түгел, чөнки, югарыда әйтелгәнчә, бу чор метрика кенәгәләре сакланып калмаган. Иске таш мәчет метрика язмаларында Ш. Мәрҗанинең Бибинәгыймә белән никахыннан туган берничә баласы теркәлгән. Бу никахтан Әхмәд 1864 елда дөньяга килә, әмма гомерле бала булмый: 1,5 яшькә җиткәч, ютәл авыруыннан вафат була[10], 1868 елда туган




*Ш. Мәрҗани һәм Бибизөһрә абыстайның улы Әхмәднең тууын, вафатын теркәгән метрика битләре. 1889 ел. 204 ф., 180 тасв., 2 эш, 340 б., 351 б. кгз.*

*The pages of the metric with the information on the birth and death of the son of Sh. Mardzhani and Bibizukhra, Akhmed. 1889. The State Archive of the Republic of Tatarstan, fond 204, series 180, file 2, p. 340 b, 351 b.*

Гайшә исемле кызлары бары тик биш ай гына яшәп кала[11]. 1871 елны 14 гыйнварда Бибихаваны тудырып ике көннән соң хатыны Бибинәгыймә 38 яшендә дөньядан китеп бара, шул ук елның декабрендә 1869 елда туган улы Салих та дүртенче яшендә вафат була[12]. Метрика кенәгәсендә 1866 елда Бибинәгыймә Хөсәен кызы белән никахта туган Мәхмүд исемле улының тууы һәм 1885 елда 20 яшендә аның сил зәхмәтеннән (үпкә авыруы) вафат булу факты да теркәлгән[13]. Үзенең дәвамчысы итеп күргән улы Мәхмүднең вафатын Ш. Мәрҗани бик авыр кичерә. Ул киләчәккә булган өметләрен шул улына баглаган була.

Шулай ук, гомерләре кыска булган кызлары Гайшәнең вафаты 1879 елда язылган, ул 18 яшькә җитеп, авырып үлә[14]. Хәдичә исемле кызының да гомере озын булмый, аның вафаты әтисе вафатыннан соң, 1889 елның 4 июлендә теркәлә[15]. Ш. Мәрҗани Бибинәгыймә Хөсәен кызы вафатыннан соң Бибифатыйма Хөсәен Муса углының кызына өйләнә. Бу никахтан туган балаларның метрика язмаларында теркәлүе очрамады. Ш. Мәрҗани гомеренең ахырында мәшһүр Габденнасыйр әл-Буави кызы Бибизөһрә белән никахлаша. Югарыда аталган Хәдичә исемле кызы Бибизөһрә исемле хатыныннан туган була. Шул ук никахтан Шиһабетдин хәзрәт вафат буласы елны, 74 яшьлек хәзрәтнең Әхмәд исемле улы туа, ул бары тик 15 көн генә яшәп калып, 27 гыйнварда бакыйлыкка күчә[16]. Моннан кала, Беренче җәмигъ мәчете метрика кенәгәләрендә Ш. Мәрҗанинең туганнары, оныкларының да туу, вафаты турындагы фактлар теркәлгән. Шундыйлардан, улы Борһанетдиннең балалары Мәрьям, Салих, Габделмәҗид хакында мәгълүматлар бар. Мәрҗаниләр нәселенең бер вәкиле Сираҗетдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗанинең 1878 елда




*Юнысовлар мәйданындагы Апанаевлар йорты.*

*The Apanayev's house on the Yunusovs Square.*

80 яшендә вафат булу факты да, аның улы Йосыф бине Сираҗетдин әл-Мәрҗанинең 45 яшендә бакыйлыкка күчүе дә Беренче җәмигъ мәчете метрикасына язылган.

Ш. Мәрҗанинең шәхесе, аның гыйльми хезмәтләре, аның мөгаллимлек эше, дини мирасы һәрьяклы өйрәнүне, тиешле бәя бирүне таләп итә. Ул татар милли җәмгыятенә, ислам өммәтенә яңа сулыш алып килгән шәхес. Аның шәхесен, иҗатын җәмгыять үзгәреше, үсеше контекстында өйрәнү – татар тарихын өйрәнүне киңәйтә һәм баета. Бу эштә яңадан-яңа, әлегә кадәр фәнни әдәбиятта киң кулланылмаган чыганаклар куллану һәрвакыт үзен аклый. Ш. Мәрҗани чорында Юнысовлар мәхәлләсенең халәтен, аның тормышын өйрәнүдә кулланылган метрика язмалары шул чорның атмосферасын, яшәү рәвешен күрсәтә. Метрика язмаларында башка документларда булмаган конкрет фактлар күренә, хәтта ки халык хәтерендә калган, әмма бик үк төгәл булмаган, яисә ялгыш булган фактлар ачыклана. Әлеге мәхәллә метрика язмалары нигезендә, Ш. Мәрҗанинең Казанда имамлык иткән еллары хакында әлегә кадәр билгеле булмаган фактлар ачыкланды. Бу да олуг галимнең тәрҗемәи хәлен һәм аның тормыш картинасын тулыландыруда кыйммәтле материал. Татар халкы тарихын өйрәнүдә, аның тормыш, яшәү рәвешен тулылыгы белән күзаллауда метрика язмалары алыштыргысыз, кыйммәтле тарихи чыганаклар булып тора.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**


1. *Салахова Э. К.* Мусульманские метрические книги России // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2018. – № 1. – Б. 81-96.
2. *Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р. Р.* Исторические мечети Казани. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – С. 10-59.
3. *Юзеев А. Н.* Звезда по имени Марджани: Документальная биографическая повесть о Шихабаддине Марджани. – Казань: Гасыр, 2005. – С. 34-41.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф., 180 тасв., 2 эш.
5. *Мәрҗани:* Фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 16-195.
6. Шунда ук.
7. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф., 180 тасв., 2 эш, 340 кгз.; *Гайнетдинов А. М.* Мәрҗани белән эпиграфик истәлекләр. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018. – 72 б.
8. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы, 204 ф., 180 тасв., 2 эш, 340 кгз.
9. Шунда ук, 403 кгз.
10. Шунда ук, 351б, 340б кгз.

11. Шунда ук, 485, 504 кгз.
12. Шунда ук, 417, 481 кгз.
13. Шунда ук, 60, 393б кгз.
14. Шунда ук, 233 кгз.
15. Шунда ук, 340 кгз.
16. Шунда ук, 340б, 351б кгз.

**Әдәбият исемлеге**

*Гайнетдинов А. М.* Мәрҗани белән эпиграфик истәлекләр. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2018. – 72 б.

*Мәрҗани Ш. Б.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.

Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – 704 б.

*Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р. Р.* Исторические мечети Казани. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 191 с.

*Юзеев А. Н.* Звезда по имени Марджани: Документальная биографическая повесть о Шихабаддине Марджани. – Казань: Гасыр, 2005. – 112 с.

**References**

Gaynetdinov A. M. *Marjani belen ehpigrafik istelekler* [Epigraphic monuments associated with Mardzhani]. Kazan, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. Institute of History publ., 2018, 72 p.

Mardzhani Sh. B. *Mostafadel-ahbar fi ahvali Kazan ve Bolgar* [The history of Kazan and Bulgar]. Kazan, The Tatar book publ., 1989, 415 p.

*Marjani: Fenni-populyar jyentyk* [Mardzhani: a popular science collection]. Kazan, Zhyen, 2010, 704 p.

Salikhov R. R., Khayrutdinov R. R. *Istoricheskie mecheti Kazani* [Historical mosques of Kazan]. Kazan, The Tatar Book publ., 2005, 191 p.

Yuzeev A. A. *Zvezda po imeni Mardzhani: Dokumentalnaya biograficheskaya povest o Shihabaddine Mardzhani* [A star named Marzhani: a documentary biographical story about Shigabutdin Mardzhani]. Kazan, Gasyr publ., 2005, 112 p.

Фотолар, күрсәтелгәннәрдән кала, мәкалә авторы тарафыннан бирелде.
The photos except for the mentioned are submitted by the author of the article.

**Сведения об авторе**

***Салахова Эльмира Кадимовна,*** кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан, e-mail: ilsalah@mail.ru

**About the author**

***Elmira K. Salakhova,*** Candidate of Historical Sciences, Senior Researcher at Sh. Mardzhani Institute of History, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, e-mail: ilsalah@mail.ru

**В редакцию статья поступила 18.08.2020, опубликована:**

*Сәлахова Э. К.* Ш. Мәрҗани чорында Юнысов мәхәлләсе (метрика язмалары нигезендә) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2020. – № 4. – С. 67-76.

**Submitted on 18.08.2020, published:**

Salakhova E. K. *Marjani chorynda Yunysov mehellese (metrika yazmalary nigezende)* [Yunusov's Mahalla of Kazan during Sh. Mardzhani's era (based on the materials of registries)]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov*, 2020, no. 4, pp. 67-76.